# «Рифкат чишмәсендә» өмә

2025 елның 17 сентябрендә Гайнетдинов Минегали һәм Таҗиев Рамиль җитәкчелегендә авылның волонтерлары «Рифкат чишмәсендә» төзекләндерү һәм чистарту эшләре оештырдылар. Бу өмәдә түбәндәге якташларыбыз катнашты: Рәфис абый Мөхетдинов, Рәфис абый һәм Тәнзилә апа Сибгатуллиннар, Саетҗан Ибатуллин, Гөлүсә апа Таҗиева (Рифкат абыйның тормыш иптәше), Гөлүсә апаның сеңлесе Гөлия һәм аның тормыш иптәше Альберт, Иван абый һәм Мәсгүдә апа Плотниковлар, Әкълимә апа Закирова, Насифуллина Розалия, Галиуллин Өлфәт (Тәкәш авылы).

Таҗиев Рифнур спонсорлыгында чишмәгә бетоннан юл салынды. Галиуллин Өлфәт техникасы белән туфрак алып килде. Шулай ук чишмә территорисендә үләннәр чабылды, чүптән чистартылды, агачлар һәм чәчәкләр утыртылды, балчык таратып газонга үлән сибелде, чишмә бинасы эчендә чистарту эшләре башкарылды. Эшләнгән эшләрдән соң чишмәнең нинди матур булып калуын түбәндәге видеода күрерсез.

Татарлардагы гадәт буенча бу изге эш Гүзәлия Гомәрова һәм Тәнзилә апа пешергән пироглар, Гөлүсә апаның өчпочмаклары белән бергәләп самовар чәе эчеп тәмамланды.

Бик зур рәхмәт бу изге эштә катнашкан киң күңелле авылдашларыбызга!